ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 октябрь, 2017 ел № 20/6

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 01 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» Федераль законның 5 маддәсенә һәм «Дәүләт куркынычсызлыгын һәм ил оборонасын тәэмин итүдә стратегик әһәмияткә ия булган хуҗалык объектларына чит ил инвестицияләре җәлеп итү тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 155-ФЗ санлы Федераль законга нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә ( Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 09 ноябрендәге № 3/5 санлы Карарлары редакциясендә), 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«8. - Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән,

- устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары өлеше 25 процентттан арткан юридик затлардан (2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ санлы Федераль законның 25 маддәсендә каралган очраклардан тыш),

- Россия Федерациясе финанс Министрлыгы раслаган салым түләүнең ташламалы режимын һәм (яйсә) финанс операцияләре башкарганда күрсәтелмәүче мәгълүмат бирүне күздә тоткан (офшор зоналары) (алга таба – офшор компанияләре) исемлеккә кергән дәүләт яки аерым җирлектә теркәлгән юридик затлардан,
- офшор компаниясе, яки офшор компаниясе кергән затлар төркеме контролендә булган юридик затлардан тыш,

физик һәм юридик затлар муниципаль милек сатып алучылар булып тора ала.

«Затлар төкеме» һәм «контроль» сүзләре 2006 елның 26 июлендәге «Конкурентлыкны саклау турында» 135-ФЗ санлы Федераль законның 9 һәм 11 маддәләрендә күрсәтелгән мәгънәләрдә кулланылалар.

Рөхсәтсез төзелгән һәм дәүләт, муниципаль милек булган җир кишәрлегендә урнашкан объект милекчеләренә, милекче бу җир кишәрлеген сатып алган очракта, әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләр кагылмый.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев